ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

«18» мая 2021 ел № 133

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 5-11 сыйныфларда сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (өйдә укучылардан тыш) укучыларны ике тапкыр бушлай тукландыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 мартындагы 81 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү һәм аны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем алучы 5-11 сыйныфларда сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән (өйдә укучылардан тыш) укучыларны ике тапкыр бушлай тукландыруны оештыру турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 26 мартындагы 81 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- түбәндәге эчтәлекле 5.1 пункт өстәргә:

«5.1. Әлеге карар 2021 елның 1 сентябреннән үз көченә керә».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Баженовага йөкләргә.

Җитәкчесе **А.Э. Акбашев**